ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2019 ел, 18 июнь **№230**

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләр өлешен) тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Апас шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

- җирлектә яшәүче һәм аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фонды төзелешен һәм эчтәлеген оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына:

Апас шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне билгеләнгән форма нигезендә тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлгә ашырылуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип күздә тотарга;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы бюджеты турында " Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын бюджет законнары нигезендә карап тикшерүгә әзерләргә һәм тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Уставы нигезендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары Л. Т. Хантимировка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль район Башлыгы **Р.Н. Заһидуллин**